МБОУ «Арская средняя общеобразовательная школа № 2»
Арского муниципального района Республики Татарстан

| «Рассмотрено» | «Согласовано» | «Утверждаю» |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО | Заместитель директора по УВР | Директор МБОУ |
| ______ Камалиева З.Н. | ______ Зиновьева .Г.Г | «Арская СОШ №2 |
| Протокол № 1 «28» | «29» августа 2024 г. | ______ Гиниатуллина Г.Г |
| августа 2024г | | Приказ №___ |
| | | от «29» августа 2024 г. |

***Рабочая программа***

по кружковой деятельности

для учащихся 1 «А» класса «Күңелле татар теле»

педагога дополнительного образования

муниципального бюджетного образовательного учреждения

«Арская средняя общеобразовательная школа № 2»

Арского муниципального района Республики Татарстан

**Ибраевой Расимы Ханифовны**

**2024 – 2025**

## Аңлатма язуы

1 нче сыйныф өчен дәрестән тыш эш программасы татар халык авыз иҗаты төрләрен,аларның яшь үзенчәлегенә туры килерлек үрнәкләрен үз эченә ала. Бу темалар балаларның телне үзләштерү дәрәҗәсенә туры килерлек итеп, метапредмет бәйләнешләрне, уку процессындагы логик эзлеклелекне искә алып сайланган һәм сәгатьләргә бүленгән.

Халык авыз иҗаты баланы сәнгать дөньясына җәлеп итү, халыкның традицияләре белән таныштыру өчен иң кулай материал булып кына калмый, образлы фикерләү үстерү, эстетик кыйммәтләргә уңай караш тудыруда да зур ярдәм итә.

Белем бирү процессын халыкның күпьеллык традицияләренә нигезләнеп кору бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрдән санала,чөнки халык җырлары, әкиятләре, уеннары, мәкаль һәм әйтемнәре баланың рухи-эстетик үсешендә төп рольне уйный , тормышны аңлауда һәм аңа яраклашуда зур ярдәм итә.

**Программаның максаты**: халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәкләрен өйрәнеп, укучыларның интеллект дәрәҗәсен үстерү, тормышка яраклашкан шәхес тәрбияләү.

Программаны тормышка ашыру барышында төркемдә һәм күмәк эшләү формалары кулланыла. Бу формалар аралашу сәләтен үстерү өчен файдалы. Бу максатка бәйле рәвештә түбәндәге бурычлар куелды:

- татар халык авыз иҗаты тарихы, жанрлары, халыкның милли киемнәре белән танышу
- халык традицияләренә, костюмына, милли мирасына кызыксыну хисләре, хөрмәт уяту
- татар халкына тирән мәхәббәт тәрбияләү.

## Дәрестән тыш эшчәнлекне үзләштерүдәге нәтиҗәләр

**“Күңелле татар теле” дәрестән тыш эшчәнлек** программасы курсының **гомуми (метапредмет) нәтиҗәләре** түбәндәгеләр:

- сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итәргә өйрәтү;
- язу һәм сөйләм осталыгын үстерү, мәсьәләне аңлый, гипотеза куя, материалны төркемли, үз фикерен дәлилли, кирәк икән – үзгәртә-төгәлләштерә, нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белергә, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алырга һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләргә күнектерү;
- баланың үз эшчәнлеген һәм әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белүенә, мөстәкыйль карарлар кабул итә һәм аларны җиренә җиткереп үти алуына ирешү;
- төрле чыганаклар белән эшләргә, аларны табарга, мөстәкыйль рәвештә кулланырга, төркемләргә, чагыштырырга, анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.

Әлеге программа түбәндәге универсаль уку гамәлләрен (УУГ) тормышка ашыруны күз алдында тота:

**Шәхси УУГ** баланың тормыш кыйммәтләрен, әхлакый һәм мораль нормаларны аңлавын һәм кабул итүен, аның әйләнә-тирәсендәге барлык нәрсәгә шәхси карашы формалашуны аңлауга юнәлгән.

**Регулятив УУГ** танып-белү процессы белән идарә итәргә булыша. Алар гыйлем туплау мәсьәләсен кабул итү күнекмәсен, билгеле бер эшчәнлекне оештыруны планлаштыру, тикшерү, үзгәрешләр кертүне, үтәлгән эшнең уңышлылыгына бәя бирүне үз эченә ала.

**Танып-белү УУГ** тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлауны, хәл итү ысулларын һәм алымнарын модельләштерүне һәм куллануны тәэмин итә.

**Коммуникатив УУГ** хезмәттәшлекне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга юнәлтелгән. Ул партнерны тыңлый һәм аңлый белүдән, мәгълүматны тулы һәм төгәл кабул итә һәм тапшыра, үзеңнең эш-хәрәкәтеңне партнер эш-хәрәкәте белән чагыштыра белүне үз эченә ала.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- халык акылы, тормыш яме, яшәү көче чыганагы булган халык авыз иҗаты турында мәгълүматлы булу
- әсәрләрнең жанрын аера белү
- киемнәрдә,бәйрәмнәрдә,аш – су өлкәсендә атар милли үзенчәлеген билгеләү
- әкият, легендаларның эчтәлеген сөйли белү
- халык җырларын, биюләре элементларын белү
- сөйләмдә мәкаль-әйтемнәр кулланырга өйрәнү
- халык уеннарын өйрәнү
- татар телендә кечкенә әсәрләрне сәхнәләштерү
- төркемдә партнер белән эшли белү
- баланың үз эшенә бәяли белүе

Эш барышында 1 нче сыйныф балаларының яшь үзенчәлекләренә туры килә торган төрләргә зуррак урын бирү күздә тотыла. Бу – уеннар , җырлар, милли кием элементлары белән танышу, рәсемнәрен ясау, табышмаклар өйрәнү, иҗат итү.

Эш программасы барлыгы 34 сәгатькә исәпләнгән.

**Тематик бүленеш**

| №п/п | Тема | Белем һәм күнекмәләр, көтелгән нәтиҗәләр | Уку эшчәнлегенең төрләре |
|---|---|---|---|
| 1 | Танышу. Дидактик уеннар. | Татар теленең байлыгын, матурлыгын аңларга тырышу, аралашканда әдәплелек кагыйдәләрен куллана белү,әңгәмәдә катнашу, бер-береңә дустанә мөнәсәбәттә булу. | Әңгәмә |
| 2 | Ребуслар чишәргә өйрәнәбез. “Татарстан шәһәрләре” . | Татарстан шәһәрләре белән танышу, игътибарлы, күзәтүчән булу, шәһәр исемнәренеә тәрҗемәсен рус телендәге тәрҗемәсе белән чагыштыру, охшаш, аермалы якларын таба белү, ребус чишәргә өйрәнү. | Ребуслар чишү |
| 3 | Дидактик уеннар “Тематик лото”. | Фикерли, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру, сораулар төзи белү, сүзләрне бер төркемгә туплый алу, ул төркемнәрне атау. | Уеннар уйнау |
| 4 | Тапкырларга – табышмак. | Фикерли, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, табышмакларны чишәргә өйрәнү һәм үзең табышмак уйлый алу, парларда һәм күмәк белән эшли белү. | Табышмаклар әйтешү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 | Кроссвордлар төзү һәм чишү. | Фикерли, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, кроссвордларны чишәргә өйрәнү, хайван атамаларын дөрес яза белергә өйрәнү | Кроссвордлар төзү |
| 6-7 | Дидактик уеннар<br>“Телеграмма”<br>“Бәхетле очрак” | Аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәнү, коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу | Уеннар уйнау әңгәмә |
| 8-9 | Шарадалар<br>“Күп укыган, күп белер”. | Шарадаларны чишә белү, җ, ң, һ хәрефләре кергән сүзләрнең дөрес әйтелешен һәм язылышын үзләштерү | Шарадалар чишү |
| 10 | Сүз уеннары “Иҗек аукционы” | Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм юлдан-юлга күчерә белү, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәнү, фикерли белү күнекмәләрен үстерү. | Сүз уеннары уйнау |
| 11 | Тизәйткеч-телебезне төзәткеч | Татар теленә хас үзенчәлекле авазларны дөрес әйтә белү, аларны ишетеп таный белү, парларда һәм күмәк эшли белү, ишетү хәтеренең күләмен үстерү. | Тизәйткечләр уку |
| 12 | Дидактик уеннар “Буяу сатышлы” | Сайланган эчтәлек аша әңгәмәдешенә кире кага, раслый белү, буяу атамаларын истә калдыру,шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру. | Уеннар уйнау |
| 13 | Башваткычлар | Фикерли, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, татар телендәге сүзләрнең сингармонизм законына бусынуын яки буйсынмавын аңлау. | Башваткычлар чишү |
| 14 | Мәкальләр дөньясында | Татар халык мәкальләре белән танышу, мәгънәләрен аңлата белү, әңгәмәдә катнашу. | Мәкальләр белән танышу |
| 15 | «Тукталышлар белән уку» алымы | Укучыларга текст исеменнән чыгып сорау куела, укучыларның фикерләре тыңланыла. Төп өлешендә текст фрагментларга бүленеп укыла, һәр өзектән соң укучылардан алга таба ни булачагы турында җаваплар тыңланыла; | Текст белән эш |
| 16 | Тел көрмәкләндергечләр | Тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү, татар теленә хас үзенчәлекле авазларны дөрес әйтә белү, аларны ишетеп таный белү, парларда һәм күмәк эшли белү. | Әңгәмә |
| 17 | Тапкырлар клубы | Әхлакый кагыйдәләрдә ориентирлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау,татар телен яхшы өйрәнү теләге формалаштыру, татар милләтенең мәдәнияте белән кызыксыну | Уен-ярыш |
| 18 | “Тәрҗемәче” уен-ярыш | Өйрәнелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү, парларда һәм | уен-ярыш |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | күмәк эшли белү, аңлаган мәгълүмат турында фикер йөртергә өйрәнү | |
| 19 | “Татарча да яхшы бел”. | Рәсем буенча җөмләләр төзү күнекмәләрен арттыру, өйрәнгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү, чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен камилләштерү. | Рәсем буенча җөмләләр төзү |
| 20 | “Ромашка” уены. Саннар | Саннарны искә төшерү, саннар кергән шигырьләрне уку, тәрҗемә итү, диалог төзү. | Уеннар уйнау |
| 21 | Комплиментлар әйтәбез | Бер-береңә комплиментлар әйтә белү, парларда һәм күмәк эшли белү | Матур сүзләр белән танышу |
| 22 | Татар халык ашлары. Дидактик уеннар “Тематик лото”. | Фикерле, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, , татар милләтенең мәдәнияте белән кызыксыну, татар халык ашлары турында мәгълүмат туплау | Уеннар уйнау |
| 23 | “Кем булып эшли?” -чы/-че сүз ясагыч кушымчалары | Әти-әниләрнең кем булып, кайда эшләвен, профессия исемнәрен әйтә белү. | Сөйләшү |
| 24 | Антонимнар. Уеннар. “Әйе-юк димәскә, ак-карага тимәскә” | Капма-каршы мәгънәле сүзләрне аерырга өйрәтү. | Уеннар уйнау |
| 25 | Синонимнар. Дидактик уеннар | Охшаш мәгънәле сүзләрне сөйләмдә куллану, чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен камилләштерү. | Уеннар уйнау |
| 26 | Омонимнар. Дидактик уеннар | Язылышы һәм әйтелеше бертөрле, мәгънәләре үзгә булган сүзләр белән танышу, рус телендәге омоним сүзләр белән чагыштыру, аларны сөйләмдә дөрес куллану. | Уеннар уйнау |
| 27 | Әдәпле сүзләр дөньясында | Әдәплелек кагыйдәләрендә ориентирлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау,татар телен яхшы өйрәнү теләге формалаштыру | Әңгәмә |
| 28 | Халык әйтсә, хак әйтә. Халык җырлары. “Әпипә” | Татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру, халык җырлары белән танышу, ошаганын ятлау. | Аудиоязма тыңлау |
| 29 | Санамышлар | Санамышлар белән танышу, аларны куллану, татар телен яхшы өйрәнү теләге формалаштыру | Санамышлар белән танышу |
| 30 | Сүз уеннары. Ребуслар | Фикерле, уйлый белү, игътибарлы, күзәтүчән булу, ребусларны чишәргә өйрәнү һәм үзең ребус уйлый алу, парларда һәм күмәк белән эшли белү. | Сүз уеннары уйнау |
| 31-32 | Проект эше “Кызыклы грамматика” | Ел дәвамында өйрәнгәннәрне кабатлау төркемнәрдә проект эшләү, аны яклау | Күмәк эш. |
| 33 | Тапкырлар һәм зирәкләр клубы | Татар телен яхшы өйрәнү теләге формалаштыру, алган белем һәм күнекмәләрне куллана белү | Уен-ярыш |
| 34 | Йомгаклау | | |

**Календар –тематик план**

| № | Түгәрәк темасы | дәрес саны | үткәрү вакыты | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт | |
| 1 | Танышу. Дидактик уеннар. | 1 | 02.09 | | |
| 2 | Ребуслар чишәргә өйрәнәбез. “Татарстан шәһәрләре” . | 1 | 09.09 | | |
| 3 | Дидактик уеннар “Тематик лото”. | 1 | 16.09 | | |
| 4 | Тапкырларга – табышмак. | 1 | 23.09 | | |
| 5 | Кроссвордлар төзү һәм чишү. | 1 | 30.10 | | |
| 6-7 | Дидактик уеннар “Телеграмма”<br>“Бәхетле очрак” | 1 | 07.10 | | |
| 8-9 | Шарадалар<br>“Күп укыган, күп белер”. | 1 | 14.10 | | |
| 10 | Сүз уеннары “Иҗек аукционы” | 1 | 21.10 | | |
| 11 | Тизәйткеч-телебезне төзәткеч | 1 | 28.10 | | |
| 12 | Дидактик уеннар “Буяу сатышлы” | 1 | 04.11 | | |
| 13 | Башваткычлар | 1 | 11.11 | | |
| 14 | Мәкальләр дөньясында | 1 | 18.11 | | |
| 15 | «Тукталышлар белән уку» алымы | 1 | 25.11 | | |
| 16 | Тел көрмәкләндергечләр | 1 | 02.12 | | |
| 17 | Тапкырлар клубы | 1 | 09.12 | | |
| 18 | “Тәрҗемәче” уен-ярыш | 1 | 16.12 | | |
| 19 | “Татарча да яхшы бел”. | 1 | 23.12 | | |
| 20 | “Ромашка” уены. Саннар | 1 | 30.12 | | |
| 21 | Комплиментлар әйтәбез | 1 | 13.01 | | |
| 22 | Татар халык ашлары. Дидактик уеннар “Тематик лото”. | 1 | | | |
| 23 | “Кем булып эшли?” -чы/-че сүз ясагыч кушымчалары | 1 | | | |
| 24 | Антонимнар. Уеннар. “Әйе-юк димәскә, ак-карага тимәскә” | 1 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 25 | Синонимнар. Дидактик уеннар | 1 | | | |
| 26 | Омонимнар. Дидактик уеннар | 1 | | | |
| 27 | Әдәпле сүзләр дөньясында | 1 | | | |
| 28 | Халык әйтсә, хак әйтә. Халык җырлары. “Әпипә” | 1 | | | |
| 29 | Санамышлар | 1 | | | |
| 30 | Сүз уеннары. Ребуслар | 1 | | | |
| 31-32 | Проект эше “Кызыклы грамматика” | 1 | | | |
| 33 | Тапкырлар һәм зирәкләр клубы | 1 | | | |
| 34 | Йомгаклау | 1 | | | |
| | Барысы | 34 | 34 | | |

## Кулланма чыганаклар

**Әдәбият исемлеге**


1. Әмиров Кафил. Акыллы кеше мәкальсез сөйләмәс. – Казан, Тат.кит.нәшр. 2011.
2. Баязитова Ф.С.”Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары”. Казан, Тат кит.нәшр., 2006.
3.Низамов И.М.”Уем тел очымда”, Казан , Тат.кит.нәшр., 2000.
4. “Сабантуй”./Под ред.И.М.Ахметзянова – Казань:НПО “Медикосервис”,1999.
5.”Сүз эчендә хикмәт бар”.Татар халык иҗаты.Казан, “Мәгариф” нәшр., 2009.
6.”Татар халык иҗаты”. Балалар фольклоры.Төзүчесе- Р.Ягъфәров.- Казан, 1993.
7.Татар халык иҗаты. Җырлар.- Казан, Тат.кит.нәшр.,1977.
8.Татар халык иҗаты. Әкиятләр.1нче китап.- Казан, Тат.кит.нәшр.1977
9.Хәбибуллина З.Н. Сәхнәләрдән әйтер сүзем бар. – Тат.кит. нәшр. 2010


## Басма чыганаклар

1. «Ялкын» балалар журналы («Пламя»).
2. «Мәгариф» («Магариф») фәнни-методик журналы.

## Электрон сылтамалар

1. Татар телендәге әдәби әсәрләр тупланган электрон китапханә // URL: http:// Kitapxane.at.ru
2. Татар телендәге видеоларга сылтама//URL:https://disk.yandex.ru/d/aWuDx4MPotjxQg/
3. Русча-татарча онлайн сүзлек // URL:www.ganiev.org.
4. «Татармультфильм» оешмасы ярдәмендә төзелгән тупланма // URL: www.tatarcartoon.ru

## Сүзлекләр

1. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1977. – Т. 1. – 476 б.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. – Т. 2. – Казан: Тат. кит.нәшр., 1979. – 726 б.